ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

«Административ хокук бозулар турында
беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи
затлар исемлеген билгеләү турында» Югары
Ослан муниципаль районы Башкарма
комитет җитәкчесенең 2018 елның 30
гыйнварындагы 102 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм «Балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 гыйнварындагы 102 номерлы карарына (07.03.2018 № 233, 06.05.2019 № 418, 26.11.2019 № 1195, 25.12.2019 № 1321, 24.01.2020 № 38, 30.04.2020 № 338, 03.07.2020 № 515, 12.11.2020 № 1095, 10.12.2020 № 1249, 19.03.2021 № 278, 21.06.2021 № 642, 25.03.2022 № 317, 04.07.2022 №652 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының иҗтимагый сак һәм тәртип пунктының (ОПОП) әйдәп баручы белгеченә ТР КоАП «Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итүне үтәмәү» 2.19 ст. буенча һәм «Гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы булган товарларны ваклап сатуны чикләмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау юлы белән куллануга җәлеп итүне үтәмәү» 2.20 ст.буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтләр бирергә.

1.2 Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенең баш белгеченә ТР КоАП «Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итүне үтәмәү» 2.19 ст. буенча һәм «Гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыеклардырылган углеводород газы булган товарларны ваклап сатуны чикләмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны сыеклардырылган углеводород газын сулау юлы белән куллануга җәлеп итүне үтәмәү» 2.20 ст.буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтләр бирергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: https://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru. бастыруырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И. Шакиров

Әзерләде:
Прозорова С.В.